# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында ветеринария эше турында" Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2007 елның 21 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында ветеринария эше турында" 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6-7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 10 (8); 2003, № 5; 2005, № 7-8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007 № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"19 статья. **Терлекләрне һәм (яисә) терлекчелек продукциясен тартып алу**";

1 өлештә "терлекләрне аерып алу һәм терлекчелек продукциясен тартып алу" сүзләрен "терлекләрне һәм (яисә) терлекчелек продукциясен тартып алу" сүзләренә алмаштырырга;

2 өлештә "авыруларның исемлеге" сүзләре алдыннан "аеручa куркыныч" сүзләрен өстәргә, "яисә" сүзен "һәм (яисә)" сүзләренә алмаштырырга;

6 өлештә "терлекләрне аерып алу яисә терлекчелек продукциясен тартып алу" сүзләрен "терлекләрне һәм (яисә) терлекчелек продукциясен тартып алу" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2008 елның I4 гыйнвары

№ 3-ТРЗ